Чыганак: Мәгариф.- 2014.- № 5.



# «Туган ягы кирәк кешегә...»

## (Г.Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» повестен өйрәнү. Рус мәктәбенең татар төркеме. VIII класс)

**Илдар САЯХОВ,**
*Казандагы 4 нче интернат-гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, «Туган тел» мастер-класс бәйгесенең җиңүчесе*

**Илдар Искәндәр улы Башкортстан якларында туып-үскән. Башкорт дәүләт педагогия институтын тәмамлаган. Белгечлеге буенча филолог. Аспирантурада укыган. Инглиз, алман, төрек телләрен белә. Өйләнгән, ике баласы бар. Мәгърифәтче, педагоглардан Р.Фәхреддин, А.Макаренко, А.Дистервегларны һөнәре буенча кумирлары итеп күрә.**

**«Укытучы белемле булганда, дәресләрен кызыклы итеп оештыра алганда гына, мәктәп яши һәм аның киләчәге өметле. ...Якты дөнья мине изге һөнәр ияләре – мөгаллимнәр юлыннан озата килүе өчен язмышыма рәхмәтле һәм бурычлымын. Унбиш буынга сузылган мәгърифәтчеләр нәселенең дәвамчысы булуыма шатланам, аның белән горурланам».**



**Максат.** «Туган ягым – яшел бишек» әсәрен өйрәнү (1 – 3 нче бүлекләр); бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү; әсәрдә туган як табигатенең гүзәллеген, табигать баласы буларак кешенең урынын билгеләү һәм татар халкының гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнү аша укучыларда табигатькә карата сакчыл караш, милли үзаң тәрбияләү һәм үстерү.

**Җиһазлау.** Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» повестен өйрәнүгә багышланган презентация, карточкалар, язучының әсәрләре, аңлатмалы сүзлек.

**Дәреснең эпиграфы:**

*Хәтерләүдән курыкма син!*
*Үткәннәрне онытма син.*
*Бел син ерак бабайларның*
*Ничек итеп көн иткәнен.*
*Нинди уйлар, нинди моңнар*
*Безгә калдырып киткәнен.* (***Р.Фәйзуллин***)

**Дәрес планы.**

**1. Оештыру өлеше**. Сыйныфта уңай психологик халәт тудыру.

**2. Өй эшен тикшерү.**

Укып килгән бүлекләр буенча фикер алышу үткәрелә, Гомәр Бәшировның биографиясенә, иҗатына кагылышлы сорауларга җаваплар алына.

**Укытучы.** Аның язучы булып китүенә нинди сәбәпләр этәргеч булган? Ул нинди әсәрләр язган? Мисаллар китерегез.

*Көтелгән җавап:* туган ягын бик яратуы, татар халкының үткәне, хәзерге хәле, киләчәге турында уйланулары, борчылуы аны язучы иткән. «Сиваш», «Намус», «Туган ягым – яшел бишек» кебек әсәрләр язган.

**Укытучы.** Язучы Г.Ахунов сүзләре белән әйтсәк: «Ул әсәрләрен очраклы вакыйгалар тәэсирендә генә, «язарга кирәк» булуы

аркасында гына язмый, юк. Нәрсәдер аны борчый, дулкынландыра. Нәрсәдер күңелен җәрәхәтли яки сөендереп, тетрәндереп уза икән, шул хакта һәм бары шуннан соң гына аңарда ул вакыйгага үзенең шәхси мөнәсәбәтен, үз сүзен әйтү теләге уяна».

**3. Актуальләштерү.**

**Укытучы.** Кадерле укучылар, бу дәрестә без дөньяда иң күркәм зат буларак яратылган кеше һәм кешелек сыйфатлары турында сөйләшербез. Г.Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» автобиографик әсәре үрнәгендә туган якка мәхәббәт, аңа карата сакчыл мөнәсәбәт, татар халкына хас милли үзенчәлекләр турында фикер алышырбыз, сөйләшербез. Дәресебезнең темасы: Г.Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» повестеның проблематикасы.

**Укытучы.** Дәресне түбәндәге шигырь юллары белән башлыйк.

*Читтә йөргән чакта, сагындырып,*
*Керер өчен төнлә төшенә,*
*Зәңгәр таңлы, биек, аяз күкле*
*Туган ягы кирәк кешегә.*
*Яшәү өчен бетмәс көч алырга*
*Олысына һәм дә кечегә,*
*Мәхәббәтле, ямьле, мәрхәмәтле*
*Туган ягы кирәк кешегә.*

**Укытучы.** Шигырьдә сүз нәрсә турында бара?

– Нәрсә соң ул туган як?

– Ни өчен ул һәр кеше өчен кирәк, шулай кадерле?

– Туган як, туган җир турында нинди мәкальләр беләсез?

*Көтелгән җавап:*

Туган илең – туган өең.

Ил йоласыз булмый.

Ир илендә кадерле h.б.

**Укытучы.** Ил йоласыз булмый. Бу мәкальгә нинди мәгънә салынган?

*Көтелгән җавап:* Һәрбер халыкның үз гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре, моңнары була.

**Укытучы.** Дәресебезнең эпиграфы белән танышып китик. Шагыйрь Р.Фәйзуллин бу юллар аша нәрсә әйтергә теләгән?

*Көтелгән җавап:* һәрбер кеше үз халкының үткәнен, әби-бабаларыбызның ничек көн иткәнен, ниләр белән шөгыльләнгәнен, гореф-гадәтләрен белергә тиеш. Чөнки үткәнен белмәгәннең киләчәге юк, ди халкыбыз.

**Укытучы.** Язучы Г.Бәшировны да нәкъ менә шул мәсьәләләр борчый. «Туган ягым – яшел бишек» автобиографик әсәрендә ул күтәргән проблемалар: табигать һәм кешенең табигатькә булган мөнәсәбәте бүген дә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе. Табигатьнең матурлыгына сокланмаган кеше юктыр. Г.Бәширов әсәрендә дә бу иң югары ноктадан торып сурәтләнгән, дияр идем мин. Ләкин барлык кешеләрнең дә табигатебезгә, җир-анабызга булган мөнәсәбәтен сакчыл дип әйтеп булмый. Шуңа күрә табигатьне саклау бурычы җәмгыятебез алдында торган бурычларның берсе булып кала бирә. Бер үк вакытта төрле милләт кешеләренең милли үзенчәлекләрен югалту, глобальләшү шартларында башка халыклар арасында югалып калу, башка милләтләр тарафыннан йотылу, дөнья йөзеннән юкка чыгу куркынычы кебек мәсьәләләр дә бүгенге көндә аеруча актуаль яңгырый. Гомәр Бәширов әсәрләре, аеруча «Туган ягым – яшел бишек» повесте безгә бу проблемаларны аңларга, төзәтергә һәм, гомумән, булдырмау юлларын өйрәтүче әсәрләрнең берсе булып тора.

**4. Уку мәсьәләсен чишү.**

**Укытучы.** Сез Г.Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек« әсәреннән өзекләр укып килдегез. Хәзер әсәрнең үзенә мөрәҗәгать итик һәм, повестьтә күтәрелгән мәсьәләләрне барлап, әсәрдән үрнәкләр табып, аларны чишү юлларын барлыйк. Мин сезгә түбәндәге тема, проблемалар буенча уйланырга, сөйләшергә, фикерләшергә тәкъдим итәм.

*(Сыйныф төркемнәргә бүленә, һәр төркемгә карточкалар таратыла. Укучылар билгеләнелгән темалар буенча*

*әзерләнгән сорауларга җаваплар әзерли. Моңлы көй уйнатыла.)*

**1 нче төркем** укучылары «Кеше һәм табигать» темасы буенча төзелгән сорауларга җавап бирә.

1. Яңасала авылы табигатен автор ничек тасвирлый? Язучының туган ягына, аның табигатенә мөнәсәбәте турында сөйләгез. Әсәрдән мисаллар китегез.

2. Үзегез яшәгән төбәкнең табигатен тасвирлагыз. Туган як табигатенә сезнең мөнәсәбәтегез нинди?

3. Табигатьне саклау юлында сез нинди эшләр башкарасыз, нинди чараларда катнашасыз?

**2 нче төркем** укучылары «Татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары» темасына кагылышлы сорауларга җаваплар әзерли.

1. Әсәрдә сурәтләнгән Яңасала авылында яшәгән татарларның көнкүрешенә караган гореф-гадәтләр, дини йолалар турында сөйләгез. Бу гореф-гадәтләр кем образларына бәйле рәвештә тасвирлана? Әсәрдән мисаллар китерегез.

2. Шушы гореф-гадәтләр, йолаларның кайсылары бүгенге көнгә кадәр сакланып калган?

3. Сез яшәгән төбәктә шуларның кайсылары сакланып килә? Сез үзегез аларның кайсыларын күргәнегез бар, кайсыларында катнашканыгыз яки үзегез оештырганыгыз бар?

**3 нче төркем** укучылары «Милли характер үзенчәлекләре» темасына төзелгән сорауларга җаваплар әзерли.

1. Повестьта сурәтләнгән образлар нинди кешелек сыйфатларына ия? Образлар үрнәгендә мисаллар китерегез.

2. Бүгенге көндә татарларда ул сыйфатлар сакланганмы?

3. Сез үзегездә шул сыйфатларның кайсылары бар дип уйлыйсыз? Үзегездә тагын нинди сыйфатлар булдырырга теләр идегез?

**5. Нәтиҗә ясау**. *(Укучыларның җаваплары тыңлана.)*

**Укытучы.** Эшебезгә нәтиҗә ясыйк. Укучылар, без бу дәрестә туган як, татар халкының милли гореф-гадәтләре, йолалары, кешелек сыйфатлары турында сөйләштек, фикерләштек. Уйлап карагыз әле, бу төшенчәләрнең кайсысы бүгенге көндә актуальрәк яңгырый?

*Көтелгән җавап:* Бу төшенчәләр бәйләнештә каралырга тиеш. Алар үзара сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләре белән тыгыз бәйләнгән. Бер милләт кешесе дә үз гореф-гадәтләре, йолалары, тел-әдәбияты, сәнгать-мәдәнияте, тарихы һәм туган ягыннан аерым карала алмый. Бу төшенчәләр, бербөтен буларак, кешедә тәрбияләнгәндә һәм үстерелгәндә генә ул чын мәгънәсендә үз милләтенең лаеклы вәкиле дип санала ала.

**6. Рефлексия.**

**Укытучы.** Шулай итеп, бу дәрестә без нәрсәләр турында сөйләштек?

Бу дәрестә без кешелек сыйфатлары турында сөйләштек. Дөньяда һәр кеше үзенең милли үзенчәлекләрен сакларга, үстерергә тиеш. Үзе яшәгән дөньяга, аны чолгап алган мохиткә, табигатькә карата игътибарлы һәм сакчыл булырга тиеш. Г.Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» исемле автобиографик повесте безгә шуны анларга ярдәм итте.

**Укытучы.** Дәресебезне йомгаклап, сезгә иҗади эш тәкъдим итәм. Бу эшебез үзенчәлекле шартларда узачак. Шуңа күрә һәрберегезнең игътибарлы булуын үтенәм. Күзләрне йомабыз. Күз алдыгызга китерегез. Сезгә әле 13 – 14 яшь, берничә елдан сезгә 17 яшь тулыр, сез, мәктәптә укуыгызны тәмамалап, үзегез сайлаган югары уку йортларына укырга керерсез, яхшы белгечләр булып, яхшы эшләргә урнашырсыз. Гаилә корырсыз, матур-матур балалар үстерерсез. Шул чакта сез бүген алган белемнәрнең бушка китмәгәнлеге турында уйларсыз.

Билгеләр куела, өйгә эш бирелә. Калган өзекләрне укып, эчтәлеген сөйләргә әзерләнеп килергә кушыла.